ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» сентябрь 2020 ел. № 284

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 июнендәге 218 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Җитештерүгә бәйле рәвештә штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 28 августында 5231исп номеры белән теркәлгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Спорт мәктәбе" муниципаль бюджет учреждениесенең 2020 елның 27 августындагы 207 номерлы үтенечнамәсен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 июнендәге 218 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 03.06.2019 № 218 карары 1 п. белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең штаттагы расписаниесен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

1.2. Төшереп калдырырга:

- 0,3 ставка штат берәмлекләре санында «Техник»;
- 0,2 ставка штат берәмлекләре санында «Кладовщик»;
- 0,1 ставка штат берәмлекләре санында «Ярдәмче эшче».

1.3. Өстәргә:

- 0,5 ставка штат берәмлекләре санында «Шәфкать туташы».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https//agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**